РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АДАВ-ТУЛУМБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АДАВ-ТОЛЫМБАЙ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«22» август 2025 ел № 45

Адав-Толымбай авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2021 елның 01 июлендәге
17 номерлы «Кулланылган терекөмешле
лампалар туплану урыннары турында»
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) турында нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 14 мартындагы 300 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге Башкарма комитетының «Кулланылган терекөмешле лампаларның туплану урыннары турында» 2021 елның 01 июлендәге 17 номерлы карарына түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә::

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Адав-Толымбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә кулланылган терекөмешле лампалар туплану урынының (урыннарының) урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Адав-Толымбай
авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе А. Ф. Әхмәтҗанов